КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 9 февраль г.Казань № 122

«Кама – 25 Октябрь 110 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектын эксплуатацияләү максатларында «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте мәнфәгатьләрендә гавами сервитут билгеләү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының V[7] бүлеге, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының саклау зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус шартларын билгеләү тәртибе турында» 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы нигезендә, «Кама – 25 Октябрь 110 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектын эксплуатацияләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Кама – 25 Октябрь 110 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектын эксплуатацияләү максатларында «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте (ИНН 1655049111, ОГРН 1021602830930) мәнфәгатьләрендә кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләренә (алга таба – җир кишәрлекләре) карата 49 елга гавами сервитут (алга таба – гавами сервитут) билгеләргә.

2. Бу карарга теркәлгән «Кама – 25 Октябрь 110 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектын эксплуатацияләү максатларында гавами сервитут чикләре урнашу урынының график тасвирламасын расларга.

3. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

гавами сервитут өчен түләүне исәпләү һәм кертү тәртибе Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{46}$ статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла;

җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану нигезендә алардан файдалану мөмкин булмаячак яки шактый авыр булачак срогы гавами сервитут срогына туры килә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бу карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә законнар белән билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

бу карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

әлеге карарның күчермәләрен «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы филиалына, «Сетевая компания» акционерлык җәмгыятенә җибәрүне.

5. «Сетевая компания» акционерлык җәмгыятенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

җир кишәрлекләренең хокук ияләре белән гавами сервитутны гамәлгә ашыру турында килешү төзүне;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының саклау зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус шартларын билгеләү тәртибе турында» 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары нигезендә «Кама – 25 Октябрь 110 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектына карата саклау зонасы чикләрен килештерү турындагы гариза белән федераль дәүләт энергетика күзәтчелеген гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына мөрәҗәгать итүне;

«Кама – 25 Октябрь 110 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектына техник хезмәт күрсәтү буенча тәэмин ителеше өчен ачык сервитут билгеләнгән план (регламент) эшләрен елга бер тапкыр гамәлгә ашыруны;

җир кишәрлекләрен аларның рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерүне;

гавами сервитут нигезендә урнаштырылган инженерлык корылмасын, тәэмин ителеше өчен гавами сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{50}$ статьясында билгеләнгән срокларда сүтүне.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин